**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чубар-Абдул авылы № 27 16 февраль 2016 ел

Чубар-Абдул авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгының 29 январь 2016 елда чыккан 2 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 29 январь 2016 елда чыккан 26 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Чубар-Абдул авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 17 апрель 2016 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   “Сез, Чубар-Абдул авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2016 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   - Авыл эчендәге юлларны ремонтлау -31 мең сум
     Чубар-Абдул авылында юлны щебенка белән каплау-20 мен сум;
     Буралы авылында юлны щебенка белән каплау-11мен сум
   - Зияратларның коймаларын төзәтү-89 мең сум
     Чубар-Абдул зияраты-32,2 мен сум
     Буралы зияраты-30 мен сум
     Мәндәй зияраты-26,800 мен сум

   ӘЙЕ ЮК
3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: Н.А.Фатхетдинов